АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.02.2020 п.г.т. Алексеевское № 292

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль**
**районының Алексеевск**
**муниципаль казна учреждениесе**
**турындагы Нигезләмәгә**
**үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасы җирле үзидарә турында» 2004 елның 08 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 21 һәм 26_3 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 һәм 16 статьяларына, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 01 маендагы 87-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 2016 елның 27 сентябрендәге 55 номерлы карары белән расланган Алексеевск муниципаль казна учреждениесе турындагы Положениегә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты

түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Компетенция һәм башкарма комитет вәкаләтләре» 4 өлештә:

- 4.2.2 пунктының 12 абзацын, 4.2.5 пунктының 14 абзацын үз көчләрен югалткан дип танырга;

- 4.2.7 пунктының 13 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«- район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының милләтара һәм конфессияара татулыгын ныгытуга, телләрен һәм мәдәниятен үстерүгә, җирле аз санлы халыкларның һәм башка милли азчылыкларның хокукла-

рын гамәлгә ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар эшли һәм гамәлгә ашыра.»;

- 4.2.9 пунктын түбәндәге эчтәлекле 7 абзац өстәргә:

« - «кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-I номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра».

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Н.К. Кадыйровны вәкаләтле дәүләт органында гамәлгә кую документларында үзгәрешләрне дәүләт теркәве буенча вәкаләтләр тапшырырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль**
**районы башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**